ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 399-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 399-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1907-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.7 һәм 5.8 статьяларны өстәргә:

«5.7 статья. **Урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплатацияләү кагыйдәләрен бозу**

1. Урам транспортыннан тыш транспортның күчмә составын һәм урам транспортыннан тыш транспорт инфраструктурасы объектларының күчмә составын эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр тарафыннан Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләре таләпләрен үтәмәү, –

вазыйфаи затларга биш меңнән ун мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме мең сумнан утыз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салуга китерә.

2. Бер ел эчендә кабатланган шул ук гамәлләр, –

вазыйфаи затларга кырык меңнән илле мең сумга кадәр; юридик затларга – ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салуга китерә.

5.8 статья. **Урам транспортыннан тыш транспорттан файдалану кагыйдәләрен бозу**

Урам транспортыннан тыш транспортның күчмә составын һәм урам транспортыннан тыш транспорт инфраструктурасы объектларының күчмә составын эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр тарафыннан Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплатацияләү кагыйдәләрен бозу, –

вазыйфаи затларга биш меңнән ун мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме мең сумнан утыз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салуга китерә.»;

2) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 7.9 статьяны өстәргә:

7.9 статья. **Урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләрен үтәүгә федераль дәүләт контроле буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы**

1. Урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләрен үтәүгә федераль дәүләт контроле буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы әлеге Кодексның 5.7, 5.8 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең баш дәүләт инженеры - Татарстан Республикасы инспекторы, аның урынбасары карый.»;

3) 8.1 статьяда:

а) 1 өлештә «7.6» саннарыннан соң «, 7.9» саннарын өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлектәге $12^1$ өлешне өстәргә:

«$12^1$. Әлеге Кодексның 5.7, 5.8 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең вазыйфаи затлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты урам транспортыннан тыш транспорт өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру максатларында эшләнде һәм урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләүне күздә тота.

«Урам транспортыннан тыш транспорт һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 442-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә урам транспортыннан тыш транспорт эшчәнлегенең хокукый шартлары һәм Россия Федерациясендә урам транспортыннан тыш транспортта халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру нигезләре билгеләнгән.

Урам транспортыннан тыш транспорт төрләренә 442-ФЗ номерлы Федераль закон метрополитенны, монорельслы транспортны, асылмалы канат юлларын, фуникулерларны кертә.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре арасында 442-ФЗ номерлы Федераль закон белән беркетелгән:

урам транспортыннан тыш транспорттан файдалану кагыйдәләрен раслау;

урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау.

Тиешле кагыйдәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 4 ноябрендәге 993 номерлы һәм 2020 елның 22 декабрендәге 1175 номерлы карарлары белән расланган.

442-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы белән пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда пассажирлар йөртүченең урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм аңа караган урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләре таләпләрен үтәү бурычы билгеләнгән. Мондый таләпләрне үтәмәү иҗтимагый куркыныч тудыра, чөнки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүгә (зыян салуга) яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зыян салу) куркынычын тудырырга мөмкин.

Административ хокук бозулар турындагы законнар нигезендә региональ норматив хокукый актларда каралган кагыйдәләрне һәм нормаларны бозган өчен административ җаваплылык Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнә.

Хәзерге вакытта Транспорт өлкәсендә федераль хезмәтнең 2022 елның 18 апрелендәге 01-10/2-333 номерлы хаты нигезендә Россия Федерациясенең барлык субъектларында урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү

кагыйдәләрен һәм урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү эше оештырылган.

Бүгенге көндә метрополитеннан файдалану кагыйдәләре һәм метрополитенны техник эксплуатацияләү кагыйдәләре белән билгеләнгән вазыйфаларны бозган өчен административ җаваплылык кертү өлешендә үзгәрешләр Санкт-Петербург законнарына кертелде.

Бәян ителгәннәр белән бәйле рәвештә, закон проекты тарафыннан югарыда күрсәтелгән таләпләрне бозган өчен юридик затларга, хосусый эшкуарларга мөнәсәбәттә административ җаваплылык кертү тәкъдим ителә.

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү һәм эшләрне карауны Татарстан Республикасында урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләрен үтәүгә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы органга - Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенә беркетү күздә тотыла.

Штрафлар күләмен билгеләү өчен Санкт-Петербургта билгеләнгән, шулай ук иҗтимагый куркыныч буенча охшаш административ хокук бозулар кылган өчен административ хокук бозулар өчен Россия Федерациясе кодексында каралган штрафларга анализ ясалды.

| Акт | Административ хокук бозу составы | Административ штраф күләме, сум. | |
|---|---|---|---|
| | | вазыйфаи затлар | юридик затлар |
| Закон проекты | 5.7 статья. Урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләрен бозу | 5 000 – 10 000 | 20 000 – 30 000 |
| | 5.8 статья. Урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу | 5 000 – 10 000<br>кабат<br>40 000 – 50 000 | 20 000 – 30000<br>кабат<br>200 000 – 500 000 |
| Санкт-Петербург административ хокук бозулар кодексы | 40 статья. Петербург метрополитеныннан файдалану кагыйдәләрен, Петербург метрополитенының техник эксплуатация кагыйдәләрен бозу | 5 000 – 10 000 | 10 000 – 30 000 |
| РФ административ хокук бозулар кодексы | 9.1 статья. Сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләрен яки куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга лицензия шартларын бозу | 20 000 – 30 000 | 200 000 – 300 000 |
| | 9.1[1] статья. Лифтларны, инвалидлар өчен күтәрү платформаларын, пассажир конвейерларын (хәрәкәт итүче җәяүлеләр юлларын) һәм эскалаторларны, метрополитеннардагы эскалаторлардан тыш, куркынычсыз куллануны һәм тотуны оештыру таләпләрен бозу | 20 000-30 000 | 300 000 – 350 000 |
| | 111.14[3] статья. Транспорт-экспедиция эшчәнлеге турындагы законнарда каралган бурычларны үтәмәү | 20 000 – 30 000<br>кабат<br>30 000 – 50 000 | 50 000 – 100 000<br>кабат<br>100 000 – 200 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 12.21² статья. Куркыныч йөкләрне ташу кагыйдәләрен бозу | 15 000 – 20 000 | 300 000 – 350 000 |
| | 20.4 статья. Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу | 20 000 – 30 000 | 300 000 – 350 000 |
| | 11.33 статья. Автобус, трамвай яки троллейбусны куллану тәртибен бозу | 30 000 | 300 000 |
| | 12.31¹ статья. Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар һәм багаж, йөк ташу куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләрен бозу | 20 000 | 100 000 |

Югарыда күрсәтелгән анализ нигезендә, республика үзенчәлекләрен исәпкә алып, закон проекты тарафыннан түбәндәге күләмдә штрафлар тәкъдим ителә:

1) урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозган өчен: вазифаи затларга – биш меңнән алып ун мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме меңнән утыз мең сумга кадәр;

урам транспортыннан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен кабат бозган өчен:

вазыйфаи затларга – кырык меңнән илле мең сумга кадәр;

юридик затларга – ике йөз меңнән биш йөз мең сумга кадәр.

2) урам транспортыннан тыш транспортны файдалану кагыйдәләрен бозган өчен: вазифаи затларга – биш меңнән алып ун мең сумга кадәр;

юридик затларга – егерме меңнән утыз мең сумга кадәр.

Закон проекты урам транспортыннан тыш транспорт өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыруны тәэмин итәчәк.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.